Дәүләт автоном һөнәри белем бирүче
“Мамадыш политехник көллияте” мәгариф учреждениесе
(ДАҺБУ “Мамадыш ПК»)

РАСЛЫЙМ

ТУ буенча директор урынбасары

_________ Фәйзреева В.В.

«25» август 2020 ел

43.01.09 Пешекче, кондитер белгечлек төре буенча

ОУД. 12 Туган тел (татар төркеме) фәненнән

**КОНТРОЛЬ-БӘЯЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ ҖЫЕЛМАСЫ**

**Контроль-бәяләү чаралары җыелмасы** урта һөнәри белем бирүнең туган тел фәне программасы таләпләренә туры китереп укытучы Әхмәтшина А.Д. тарафыннан эшләнде.

Гомумуманитар һәм социаль – икътисадый фәннәр буенча методик комиссия утырышында каралды, расланды.

Протокол №1

«26» август 2020 ел

Зав. ПЦК ________/ Л.В. Ямалиева
имза, инициаллар фамилия

**Эчтәлек**

**Фәннең максаты һәм бурычлары........................................................................4**

**Фәнне үзләштерү, тикшерү эшләре. Биремнәр.......................................................5**

**Кулланылган әдәбият...........................................................................................17**

**Уку фәнен үзләштерүне тикшерү һәм бәяләү.........................................................17**

1.1 **Контроль-бәяләү чаралары җыелмасы** урта һөнәри белем бирүнең туган тел фәне программасы таләпләренә туры китереп эшләнде.

1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү
2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.
3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.
4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълумат алу.

**Фәннең максаты һәм бурычлары:**

Дәресләрдә бирелә торган белем, осталык һәм күнекмәләрнең күләме җәмгыятебезнең иҗтимагый функцияләренә туры китереп билгеләнә. Төп идеясе - укытуның фәнни һәм гамәли нигездә оештырылуы, телне тирәнтен белү, туган тел ярдәмендә үзара иркен аңлашу, уй-фикерләреңне һәм хис – тойгыларыңны дөрес һәм төгәл итеп белдер укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, сөйләм һәм язма телен үстерү белән беррәттән, рухи дөньясын баету, реаль чынбарлыкка дөрес караш формалаштыру, тормыш вакыйгаларына хәбәрдарлыгын тәэмин итү; татар теленнән алынган теоретик материалны (тел системасын) аңлап үзләштерүне һәм тел фәнен яхшы белүне тәэмин итү; гамәли тел материалларын хәтердә калдырып һәм тәрбияви максатны күздә тоткан хәлдә, әдәбият дәресләре программасында бирелгән текстларны анализлый белү, изложение һәм сочинениеләрне логик фикерләп, телдәге сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы кулланып, грамоталы итеп һәм дөрес каллиграфия белән яза белүләренә ирешү, идея дәрәҗәсенең югары булуын тәэмин итү, текст өстендә эшләү күнекмәләрен камилләштерү, үзеңнең һәм иптәшләреңнең кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, информация чыганакларыннан кирәкле мәгълүматларны таба һәм куллана белергә өйрәтү;укучыларда дәреслек һәм өстәмә әдәбияттан (әдәби әсәрләре, фәнни чыганаклар, төрле сүзлекләр, вакытлы матбугат) дөрес файдалану күнекмәләрен үстерү, план, тезис, конспектлар төзү, эш кәгазьләрен (деловые бумаги) дөрес һәм грамоталы язарга өйрәтү; бәйләнешле сөйләм культурасын үстерү өчен, укучыларда укыганны һәм сөйләгәнне кабул итү, сөйләмнән урынлы файдалану осталыгын (уку,язу,сөйләү,тыңлау, аңлау, сөйләшү, аралашу, диалогик һәм монологик сөйләм) иҗади эш башкару күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр**

Укучылар үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:
1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү
2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.
3. Сүз төзелеше, сүзясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.
4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълумат алу.

**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**

1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.
2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.
3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау
4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.
5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.
6. Орфографик принциплар һәм аларның нормаларын белү.
7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.
8. Пунктуация кагыйдәләреннәндөресфайдалану.
12. Матур әдәбият әсәрләрен укып – сөйләм дәрәҗәсен арттыру.

## ФӘННЕ ҮЗЛӘШТЕРҮ, ТИКШЕРҮ ЭШЛӘРЕ. БИРЕМНӘР

**Тикшерү эше №1**. Кереш тикшерүе:диктант

**Максат:**укучыларның уку елы башындагы белем дәрәҗәләрен тикшерү,

**Тикшерү эшенең эчтәлеге** тыныш билгеләрен дөрес итеп куюга юнәлтелгән:

- тиңдәш кисәкләр янында,
- кушма җөмләләрдә.

**Грамматик биремнәр:**

- сүз төзелеше ( сүзләрне тамыр, кушымчаларга аеру),
- җөмләнең баш кисәкләрен табу,
- җөмлә кисәкләренә морфологик-синтаксик анализ ясау.

**Критерии оценки знаний учащихся на грамматическое задание:**

Отметка «5» ставится за 95-100% правильных ответов
отметка «4» ставится за 94-85% правильных ответов
отметка «3» ставится за 84-50% правильных ответов
отметка «2» ставится, если правильно выполнено менее 50% заданий

**Критерии оценки знаний учащихся:** диктант.

Отметка «5» выставляется за безошибочную работу;
отметка «4» выставляется при наличии 2 орфографических, 2 пунктуационных, или 1 орфографической и 3 пунктационных ошибок;
отметка «3» выставляется при наличии 4 орфографических, 4 пунктуационных, или 3 орфографической и 5 пунктационных ошибок;
отметка «2» выставляется выставляется при наличии 7 орфографических, 6 пунктуационных, или 6 орфографической и 5 пунктационных ошибок;

*Диктант.Болытлар сәяхәте.*

Мин бакчада утырам. Күк йөзе чалт аяз. Бу җәйге көннәрдә ул юып куйгандай чип-чиста. Әнә ерак офык итәгеннән бер болыт йөзеп чыкты. Әкрен генә, тыныч кына килә. Күңелемне шатлык хисе биләп алды: болыт килә, болыт!

Күрәм, ул болыт мәһабәт ир кешегә охшаган иде. Күктә бик салкын, күрәсең. Әнә ул башына ак колакчын бүрек киеп куйган. Җилкәсендә бөдрә тун. Муенын кат-кат шарф белән ураган, һич шигем юк, бу — Әткә болыт.

Аның янәшәсендә генә тагын бер болыт. Бусы — Әнкә болыт. Зифа буйлы, чәчләре ташкын төсле дулкынланып тора. Менә озак та узмады, Әнкә болыт артыннан янә дә бер кечкенә генә болыт күренде. Ул әле рәтләп йөзә дә белми кебек. Як-якка авышкалап бара да аптырап туктап тора. Әлбәттә, бу – Бала болыт, дидем мин үз-үземә. Әйе, әйе, Бала болыт! Алар өчәү зәңгәр киңлек буйлап сәяхәт итәләр. *(Н.Дәүлидән)* (135 сүз)

***Бирем.***

***1.*** Итәгеннән, күңелемне, башына, колакчын, җилкәсендә, дулкынланып, өчәү ***сүзләрен тамыр һәм кушымчаларга аерыгыз.***

***2.*** Әнә ерак офык итәгеннән бер болыт йөзеп чыкты ***җөмләсендәге баш һәм иярчен кисәкләрне табыгыз, җөмлә кисәкләренә морфологик-синтаксик анализ ясагыз.***

***3.*** Җәйге, итәгеннән, бер, озак, алар ***сүзләренә морфологик анализ ясагыз.***

**Тикшерү эше №2. Диктант.** Тема:Фонетика,орфорграфия, графика, орфоэпия.

**Максат:**укучыларның фонетика бүлеге буенча белем дәрәҗәләрен тикшерү,

**Тикшерү эшенең эчтәлеге** фонетик принципларны дөрес итеп куллануга юнәлтелгән:

- сүзләрне дөрес итеп транскрипцияләү;
- сингармонизм законын дөрес файдалану белү.

**Грамматик биремнәр:**

- сүз төзелеше ( сүзләрне тамыр, кушымчаларга аеру),
- сингармонизм законын дөрес файдалану табу,
- җөмлә кисәкләренә морфологик-синтаксик анализ ясау.

**Критерии оценки знаний учащихся на грамматическое задание:**

Отметка «5» ставится за 95-100% правильных ответов
отметка «4» ставится за 94-85% правильных ответов
отметка «3» ставится за 84-50% правильных ответов
отметка «2» ставится, если правильно выполнено менее 50% заданий

**Критерии оценки знаний учащихся:** диктант

Отметка «5» выставляется за безошибочную работу;
отметка «4» выставляется при наличии 2 орфографических, 2 пунктуационных, или 1 орфографической и 3 пунктационных ошибок;
отметка «3» выставляется при наличии 4 орфографических, 4 пунктуационных, или 3 орфографической и 5 пунктационных ошибок;
отметка «2» выставляется выставляется при наличии 7 орфографических, 6 пунктуационных, или 6 орфографической и 5 пунктационных ошибок;

Диктант. Әкияти манзара.

Зариф, урманны узып, болынга килеп чыкты. Ай яктысында алиһәдәй җәелеп яткан болын! Күл буенда атлар пошкыра, кырыкмыш кешнәп куя, таен янына дәшеп, карт бия кешни. Карамалы халкы өчен бу болын – печән. Ә печән ул мал-туар, димәк, ит-сөт дигән сүз. Болынга ялганып, Зур күл ялтырый. Күл ярына килеп җиткән усак урманы биек дивардай тора. Яз килдеме, Ык ташый. Тау-уйдыклардан, чокыр-чакырлардан агып төшкән язгы сулар Ык бозларын күтәрә. Күп тә үтми, мунча биеклек бозлар, яман тавышлар чыгарып, шушы усак урманына ташлана. Ястык-ястык бозлар, этешә-төртешә, бер-берсенә бәрелешкән саен уала-чәрдәкләнә; урман авызындагы шомырт-баланнарны, гөлҗимеш-карлыганнарны егып, гаскәр кебек тезелеп торган усакларга ябырылалар. Яшәү дәверләрендә бик күп язларны, хәтәр ташуларны күргән бозлар бәрелгәннән кәүсә-кайрылары яраланып беткән агачлар ыңгырашып куялар. Шартлап, ботаклары сына, яшел күлмәкләре уела, әмма бозларга юл бирмиләр. Бозлар ачу аталар, берсе өстенә берсе үрмәләп менә торгач, ярылып китәләр һәм ухылдап мәтәлеп төшәләр. Буыла, тыгыла елга; су үзенә юл эзли башлый. Анда ташлана, бире ургыла, ахыр килеп, бәрәңге бакчалары, тыкрыклар аша авылга керә.

*(М.Хәбибуллиннан)* (160 сүз)

**Бирем.**

**1.**Сүзләрнең транскрипциясен языгыз:
Болынга, язылган, пошкыра, яман, ярылып, биеклек, дәү, авыл, бия, карт, ямаулык, егетләр, йөзә, русча, күзге.

**2.**Ирен һәм рәт гармониясенә мисаллар табып әйтегез, транскрипциясен языгыз**.**
Үрнәк:болыт – [болот] , кызларга - [къызларгъа], .....

**3.**Ирен армониясе чагылыш тапкан сүзләрне табарга, мәкальләрнең мәгънәсен аңлатырга**:**
Теләгең саф булса, тормышыңда тап булмас.
Кояшның матурлыгы – төсендә, кешенең матурлыгы – эшендә.

**Тикшерү эше №3.** Диктант. Тема: Лексика

**Максат:**укучыларның лексика бүлеге буенча булган белем дәрәҗәләрен тикшерү,

**Тикшерү эшенең эчтәлеге** лексика буенча булган дөрес итеп куллануга юнәлтелгән:

**Грамматик биремнәр:**

- синоним парларын табу;
- сүзнең туры, күчерелмә мәгънәсен дөрес табу;
- сузык, тартык авазларны язуда дөрес куллану.

**Критерии оценки знаний учащихся:** диктант

Отметка «5» выставляется за безошибочную работу;
отметка «4» выставляется при наличии 2 орфографических, 2 пунктуационных, или 1 орфографической и 3 пунктационных ошибок;
отметка «3» выставляется при наличии 4 орфографических, 4 пунктуационных, или 3 орфографической и 5 пунктационных ошибок;
отметка «2» выставляется выставляется при наличии 7 орфографических, 6 пунктуационных, или 6 орфографической и 5 пунктационных ошибок;

**Критерии оценки знаний учащихся на грамматическое задание:**

Отметка «5» ставится за 95-100% правильных ответов
отметка «4» ставится за 94-85% правильных ответов
отметка «3» ставится за 84-50% правильных ответов
отметка «2» ставится, если правильно выполнено менее 50% заданий

Диктант.Туган җир

Туган илне сагыну дигән хис тә төрле дәрәҗәдә, төрлечә була икән.

Менә син чит ил урамнарында ялгыз йөреп кара. Шагыйрь әйтмешли, син кем кадерлесе анда? Кинәт авырдың, ди. Докторга күренү өчен күпме доллар кирәк? Синең өчен анда беркем дә җавап бирми, син анда берәүгә дә кирәк түгел. Чит дөньяның иң эре башкаласында, иң зур урамның уртасында син-ком бөртеге,син-нуль.Ватан дигән газиз җирне әнә шунда син бөтен нечкәлеге белән аңлый башлыйсың. Мин бу хисне күп тапкырлар дөньяның күп калаларында кичердем.Бу хис бер җирдә минем күңелемнән китмәде.

Чын сагыну үзен шунда танытты.

Һәркемнең үз бала чагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар. Һәркем дөньяда безнең шәһәрдән, авылдан, чишмәдән, таудан матур урын юк дип ышанып яши бирә.

Җир шарында алты кыйтга бар, алар һәрберсе үзенчә матур. Әмма иң матуры-син туган, син үскән җир.Шуңа күрә туган җирнең, әти-әнинең кадерен белергә,сөенеп яшәргә кирәк. ("Ватаным Татарстан" газетасыннан) (150 сүз)

**Бирем.**

1.Синоним парларын табарга: кыйтга, матур, дөнья, нечкә, газиз,эре, сөенү, авыру, кала,доктор.
2.**Тел** сүзенең төп һәм күчерелмә мәгънәләрен кулланып, җөмләлә төзеп языгыз.
3. **Чын сагыну үзен шунда танытты** җөмләсенә морфологик –синтаксик анализ ясарга.

**Тикшерү эше №4.** Диктант. Иң кадерле кешем.

**Максат:**укучыларның морфлогия бүлеге буенча булган белем дәрәҗәләрен тикшерү,

**Тикшерү эшенең эчтәлеге** морфология буенча булган белемнәрен дөрес итеп куллануга юнәлтелгән:

**Грамматик биремнәр:**

- алмашлыкларны табу,килешләрен дөрес билгеләү;
- сүз төркемнәре янында тыныш билгеләрен дөрес кую;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау тәртибен дөрес куллану.

**Критерии оценки знаний учащихся:** диктант

Отметка «5» выставляется за безошибочную работу;

отметка «4» выставляется при наличии 2 орфографических, 2 пунктуационных, или 1 орфографической и 3 пунктационных ошибок;
отметка «3» выставляется при наличии 4 орфографических, 4 пунктуационных, или 3 орфографической и 5 пунктационных ошибок;
отметка «2» выставляется выставляется при наличии 7 орфографических, 6 пунктуационных, или 6 орфографической и 5 пунктационных ошибок;

**Критерии оценки знаний учащихся на грамматическое задание:**

Отметка «5» ставится за 95-100% правильных ответов
отметка «4» ставится за 94-85% правильных ответов
отметка «3» ставится за 84-50% правильных ответов
отметка «2» ставится, если правильно выполнено менее 50% заданий

Диктант. Иң кадерле кешем.

1) Дөньяда һәркемнең иң кадерле кешесе була. 2) Ул тормышыңның иң *авыр* минутларын да, бәхетле мизгелләрен дә уртаклаша. 3) Аның сүзләре ќанга дәва бирә, күзләре ышаныч һәм *өмет* өсти.

4) Әнием – дөньядагы иң *кадерле*, якын кешем. 5) Күңелем тулган чакларымда әниемнең ќылы сүзләре мине юата, дәрт һәм рух өсти. 6) Күңелемне шатлык биләп алса, әнием аны да ихлас күңеленнән уртаклаша. 7) Мәктәптән канатланып кайтканда, әниемнең йөзе кояш кук балкый.

8) Еллар аның кара бөдрә чәчләренә чал керткән, кайгы–хәсрәт битләренә ќыерчыклар өстәгән. 9) Язмыш аны төрлечә сыный. 10) Әмма ни генә булмасын, әнием безне кешедән ким–хур булмасыннар дип, аякка бастырырга, чын кеше итәргә тырышкан. 11) Ул безнең өчен яши. 12) Әнием – җирдәге фәрештәм. 13) Әнием – безнең горурлыгыбыз һәм таянычыбыз. 14) Рәхмәт сиңа, әнием! 15) Без бәхетле тик син булганда! 16) Әнием дип әйтүдән дә олырак бәхет *юк* дөньяда! (123 сүз)(«Ялкын» журналыннан)

1.Алмашлыкларны табарга, килешләрен билгеләргә.

2. Текстның язылу стилен билгеләгез:

1) рәсми эш стиле; 2) публицистик стиль; 3) фәнни стиль.

3. 4 нче, 12 нче, 13 нче җөмләләрдә сызык куелу сәбәбен аңлатыгыз.

4. 2 нче, 3 нче, 4 нче, 16 нчы җөмләләрдәге билгеләнгән сүзләрнең әйтелеше белән язылышы туры киләме? Шул сүзләрнең берсенә фонетик анализ ясагыз.

5. 13 нче җөмләдәге *горурлыгыбы*з сүзенең төлешен һәя ясалышын тикшерегез.

6. 10 нчы җөмләдә ни өчен өтерләр куелуын аңлатыгыз.

7. 9 нчы җөмләдәге *язмыш, төрлечә* сүзләре кайсы сүз төркемнәренә керә? Аларга морфологик анализ ясагыз.

**Тикшерү эше №5.** Изложение. *Татарстан нефте.*

**Максат:** укучыларның укылган текстны план буенча дөрес итеп язу, җөмләләрне дөрес итеп төзү, сөйләм телен һәм язу күнекмәләрен үстерү

Язма эшне бәяләү критерийлары

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш. Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.Тыңлаган текстка карап язылмаган эшкә билге куелмый.

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган барлык мәсьәләләр язма эштә урын алган. | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган | 2 |
| **ИК2** | **Изложениенең бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Эшнең эчендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бөтенлеге, эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән. | 2 |
| | Эшнең эчендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле, эзлекле булуы күзәтелә.<br>Әмма 1 логик хата бар<br>Яки кызыл юлны билгеләүдә 1 хата бар.<br>Эштә коммуникатив мәгънә сакланган<br>Әмма бердән артык логик хата<br>Яки кызыл юлны билгеләүдә ике хата бар | 2<br><br><br><br>0 |
| **ИК3** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен, төгәлләнгән,текст төзүдә хата юк | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен, төгәлләнгән, ләкин текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки аннан да күбрәк хата бар. | 0 |
| **ИК4** | **Дәлил мисалларның булуы** | |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән | 4 |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләүнең берсе генә текстка карый | 3 |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләүне тормыш тәҗрибәсеннән чыгып билгели | 1 |
| | Укучы бер генә дәлил китергән | 1 |
| | ИК1-ИК2 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл | 20 |

Изложение өчен түбәндәге билгеләр куела

0 - 5 балл – “2” ле билгесе

6 – 10 балл – “3”ле билгесе

11- 15 балл – “4”ле билгесе

16-20 балл - “5” билгесе куела

Изложение. *Татарстан нефте.*

Кешелек дөньясының гаҗәеп бер хасияте бар: инде ирешеләсенә ирешелде, тикшереләсе тикшерелде, шуннан ары булмас, дисең. Юк, каяндыр бер тынгы-сыз җан килеп чыга, әнә шул тынгысыз җан дөнья галимнәре белән пычакка пычак килә; үзенчә уйлап, үзенчә фикер йөртеп, үзенчә исәпли башлый. Карыйсың – булмастайны булдыра, адәм ышанмастайга ышандырып куя.

Гасырларга берничә генә туа торган әнә шундый тынгысыз җаннарның берсе – Иван Губкин.

Гаҗәеп кеше булган Михайло малае Иван. Ока елгасы буендагы Муром тирәсе авылларының берсендә туып, бала чагын көтү көтеп уздырган. Бөтеркәч башлы, каш астыннан карап йөри торган үсмер малай, сыерлары чирәм утлап йөргән чакларда, яр өсләреннән түбәнгә шуып төшә. Текә ярлар пычак белән телеп төшергән төсле! Җир кабыгы катлы-катлы. Бу бик тә сәер тоела малайга. Көзен, мал-туар абзарларга ябылгач, Иван мәктәпкә йөри. Зирәклеге, тырышлыгы белән танылып, укытучылар семинариясенә барып керә.

«Бу кеше үз юлын тапты инде, бөтен гомерен балалар укытып уздырыр инде», – дигәннәр авылдашлары. Авыл укытучысы ала торган унбиш сум жалованье сала мужигына буй җитмәс хәзинә булып тоелган. Ләкин Михайло малаеның күңелендә башка уй: актарасы иде тауларны, гизәсе иде дөньяларны!

Укытып алган акчасын ай саен яшерен янчыгына җыя барып, кирәк кадәр мая туплагач, хыялый егет аркасына юл капчыгы аса да Питер каласына юл тота. Анда реаль мәктәп буенча үзлегеннән имтихан тапшырып, Тау институтының мәрмәр баскычларына килеп баса.

Яһу! Бер урынга унар кеше туры килә торган имтиханга генерал балалары, купец-чиновник балалары җыелган чакта, кая инде ул мужик баласына анда борын төртү! Ләкин могҗиза: мужик баласы дигәнебез, белем байлыгы һәм кыю фикерләре белән имтихан алучыларны таң калдырып,

институтка уза. Ярлы-ялчы хәлендә яшәп, ял көннәрендә Невада баржалар бушатып, җан-фәрманга тырыша торгач, китә эшләр җайга: сәламәт тәненә җегәр, зирәк башына белем җыйган Иван Михайлович Губкин, 1912 нче елның көзендә тау инженеры дигән беренче дәрәҗәле дипломны күкрәк кесәсенә салып, туп-туры Майкопка юнәлә.

Башлана шуннан тынгысыз эзләнүләр.

Көтүче - академик дип даны чыккан искиткеч зур галим нефть геологиясе буенча дөньяда иң яхшы дәреслекләрне яза. Икенче Баку районнарында – Иделдән алып Уралга хәтле булган гаять зур иңкүлектә – нефть эзли.

Дөньяга даны таралган укымышлылар бәхәсләшә Губкин белән. Ләкин көтүче-академик сүзендә нык тора. Аның кебек алдан күрү, аның кебек прогноз куя белү сәләте бирәүдә дә булмый. Егерме еллык авыр хезмәт, егерме ел буена түгелгән маңгай тире бушка китми. 1932 нче елда безнең кардәш республикабыз Башкортстан туфрагында – Ишембайда сигез йөз метр тирәнлектән нефть фонтаны атып, агач буровойны күз ачып йомганчы йомычкага әйләндереп ташлый! Аннары Татарстан җирендә – Шандорлар, Нобельләр, Малакиенколар шөһрәт казана алмаган җирләрдә – Шөгердә, Баулыда, Писмән якларында бер-бер артлы нефть фонтаннары ата.

Әнә шул көннән башлап, иксез-чиксез Ватаныбызның барлык якларыннан олы хәзинә җирләренә илнең осталары җыела башлады. Алар арасында кайчандыр бәхет эзләп чыгып киткән татар эшчеләре дә бар иде. *(Г.Ахуновтан)* (255 сүз)

**Тикшерү эше №6. Тема:** Морфология бүлеген йомгаклау.

**Максат:**укучыларның морфология бүлегеи буенча булган белем дәрәҗәләрен тикшерү,
**Тикшерү эшенең эчтәлеге** морфология буенча булган белемнәрен тикшерүгә юнәлтелгән:

**Эталон**

| № | 1 вариант | 2 вариант | 3 вариант | 4 вариант |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ә | Ә | Б | Б |
| 2 | А | В | Ә | Ә |
| 3 | Ә | Б | Б | Б |
| 4 | Б | Ә | Б | Б |
| 5 | А | Б | Ә | А,Г |
| 6 | Б | А | Е | А |
| 7 | А | Ә | А | Б |
| 8 | А | Ә | Г | Ә,Б |
| 9 | Ә | Б | А | А |
| 10 | Б | А | Б | Б |

**I вариант**

1. Рәвеш нәрсәне белдерә?
*а) предметның билгесен;*
*ә) билгенең билгесен;*
*б) эш – хәл, хәрәкәтне.*
2. Рәвеш нинди сорауларга җавап бирә?
*а) ничек? кайда? кайчан? күпме?*
*ә) нинди? кайсы? ничек? кая?*
*б) күпме? нәрсәне? кая? нишләгәч?*
3. Рәвешнең ничә төркемчәсе бар?
*а) дүрт;*

*ә) алты;*
*б) җиде.*
4. Рәвешнең үзенә генә хас нинди билгесе бар?
*а) зат – сан белән төрләнә;*
*ә) исемләшә;*
*б) төрләнми.*
5. Рәвеш, күбрәк, җөмләнең кайсы кисәге була?
*а) хәл;*
*ә) тәмамлык;*
*б) аергыч.*
6. Төзелеше ягыннан нинди рәвешлшр була?
*а) тамыр, ясалма, парлы;*
*ә) кыскартылма, ясалма, тамыр;*
*б) тамыр, ясалма, кушма, карлы, тезмә.*
7. Җөмләләрдә рәвешләр нинди җөмлә кисәге булып килгән?
*Шактый биек ярда басып торабыз. Бүген дә кыр казларын күзәтәбез. Быел, нидәндер, алар бик аз.*
*а) хәл, хәл, хәл, хәл, хәбәр;*
*ә) хәл, аергыч, хәбәр, хәл, хәл;*
*б) ия, хәл, аергыч, хәл, хәбәр*
8. Рәвешләр нинди дәрәҗәләрдә килә ала?
*а) артыклык, чагыштыру, кимлек;*
*ә) гади, кимлек, чагыштыру;*
*б) чагыштыру, артыклык.*
9. Рәвешләрнең төркемчәләрен әйтегез.
*Былтыр, байтак, чәчәктәй, ерак, юкка, тиз*
*а) вакыт, күләм – чама, охшату – чагыштыру, урын, сәбәп – максат, саф;*
*ә) саф, күләм – чама, вакыт, охшату – чагыштыру, сәбәп – максат, урын;*
*б) күләм – чама, урын, вакыт, сәбәп – максат, охшату – чагыштыру, саф.*
10. Рәвешләрнең ясалышын әйтегез.
*Бервакыт, иртә - кич, күз ачып йомганчы, көмештәй, кинәт*
*а) тамыр, парлы, тезмә, кушма, ясалма;*
*ә) кушма, парлы, тезмә, ясалма, тамыр;*
*б) кушма, парлы, тезмә, тамыр, ясалма.*

**II вариант**
1. Татар телендә ничә килеш бар?
*а)5;*
*ә) 6;*
*б) 8.*
2. Сыйфатның дәрәҗәсен өйтегез.
*Җете кызыл.*
*а) кимлек;*
*ә) чагыштыру;*
*б) гади;*
*в) артыклык*
3. Кимлек дәрәҗәсе ясаучы кушымчаны билгеләгез.
*а) – рак/ - рәк;*
*ә) – лы/ - ле;*
*б) –сыл/- сел.*
4. “Никтер чәчәкләрнең акларына бал кортлары ешрак килеп куна” җөмләсендәге сыйфатның үзгәрешен нинди күренеш дип атыйлар?
*а) сыйфатның исемне ачыклап килүе;*

*ә) сыйфатның исемләшүе;*
*б) килеш, тартым, күплек белән төрләнүе.*
5. Мәгънәләре ягыннан рәвешләр ничә төркемчәгә бүленә?
*а) 4;*
*ә) 5;*
*б 6.*

6. Кайсы төркемчәгә кергән саннар килеш белән төрләнми?
*а) бүлем саны;*
*ә) тәртип саны;*
*б) җыю саны.*
7. Алмашлыклар төзелешләре ягыннан нинди алмашлыклар?
*Барлык, андый, тегеләй, ниндидер.*
*а) тамыр алмашлык;*
*ә) ясалма алмашлык;*
*б) кушма алмашлык.*
8. Алмашлыкларның төркемчәсен билгеләгез.
*Һәркем, һәркайсы, һәммә, бөтен, бар, үз.*
*а) билгесезлек алмашлыклары;*
*ә) билгеләү алмашлыклары;*
*б) күрсәтү алмашлыклары.*
9. Фигыльләр нәрсәләр белән төрләнә?
*а) заман белән;*
*ә) килеш белән;*
*б) барлык – юклык, заман, зат – сан белән.*
10. Сөйләр (сүз), башланыр (көн), китәр (чак), куяр (урын) сыйфат фигыльләре кайсы заманда килгән?
*а) үткән заманда;*
*ә) хәзерге заманда;*
*б) киләчәк заманда.*

**III вариант**
1. Тамырга ялганып, яңа сүз ясый торган кушымчалар:
*а) төрләндергеч кушымчалар;*
*ә) төр кушымчалары;*
*б) сүз ясагыч кушымчалар.*
2. Бер үк тамырдан төрле ясагыч кушымчалар ялгап,
*а) синонимнар ясап була;*
*ә) тамырдаш сүзләр ясап була;*
*б) антонимнар ясап була.*
3. Исемгә кушымчалар түбәндәге тәртиптә ялгана:
*а) башта – килеш, аннан соң тартым кушымчасы;*
*ә) башта - тартым., аннан соң килеш кушымчасы;*
*б) башта – күплек, аннан соң тартым кушымчасы.*
4. Баш килештәге эндәш сүз
*а) җөмлә кисәге итем карала;*
*ә) җөмлә кисәге итеп кралмый.*
5. Юнәлеш килешендәге исем эш яки хәлнең
*а) билгеле бер урынын белдерә;*
*ә) билгеле бер затка яки предметка юнәлгәнлеген белдерә;*
*б) вакытын белдерми;*

*в) максатын һәм сәбәбен генә белдерә;*
*г) үтзлү вакытын, максатын, сәбәбен, билгеле бер урынга, затка яки предметка юнәлгәнлеген белдерә.*
6. Җыю саны
*а) предметның төгәл исәбен белдерә;*
*ә) предметның тәртип буенча санын белдерә;*
*б) предметның тигез өлешләргә бүленешен белдерә;*
*в) предметның якынча исәбен белдерә;*
*г) предметлык төшенчәсен белдерә*
*е) төрдәш предметларны бер төркемгә җыя.*
7. Тартым алмашлыклары
*а) сан һәм килеш белән төрләнә, җөмләдә ия, хәбәр, тәмамлык булып килә;*
*ә) төрәнми, җөмләдә гел иярчен кисәк кенә булып килә;*
*б) төрләнми, җөмләдә, нигездә, хәбәр булып килә.*
8. Парлы саннар,
*а) микъдар саны булып килә;*
*ә) тәртип саны итеп карала;*
*б) бүлем саны итеп карала;*
*в) җыю саны итеп карала;*
*г) чама саны булып килә.*
9. Исем-
*а) сан, тартым, килеш белән төрләнә;*
*ә) барлык – юклык белән төрләнә;*
*б) җөмләдә ия, тәмамлык, аергыч, хәл булып килә;*
*в) үзенә бәйләнгән исемнең билгеле бер килештә килүен таләп итә.*
10. Төшем юнәлешендәге фигыльләрне күрсзтегез.
*а) яшәргә, сөйләшкән, тынычлап, тели;*
*ә) алынгансың, төренмичә, сөйләнеп, эшләнми;*
*б) басылган, күтәрелмичә, бизәлер, тарала;*
*в) көрәштең, уйлашсаң, җитешмәсәк, аңлаштык;*
*г) кышланган, теләнгән, сызланмаган, көйләнмәгән.*

**IVвариант**

1. Сызыкча аша  языла торган ялгызлык исемнәрнең
*а) икесе дә баш хәрефтән языла;*
*ә) берсе генә баш хәрефтин языла;*
*б) беренчесе генә баш хзрефтән языла.*
2. Рәвеш-
*а) эш яки хәлнең билгесен белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме;*
*ә) билгенең билгесен белдерә торган сүз төркеме;*
*б) эш яки хәлнең, билгенең билгесен белдерә торганмөстәкыйль сүз төркеме.*
3. Уртаклык, җыелмалык төсмерен аңлатып килгәндә, ялгызлык исемнәргә
*а) күплек кушымчасы ялганмый;*
*ә) күплек кушымчасы ялгана;*
*б) күплек кушымчасы ялганырга да, ялганмаска да мөмкин.*
4. Исем һәм исемләшкән сүзләр урынында йөри торган алмашлыклар җөмләдә
*а) җөмләнең баш кисәкләре булып килә;*
*ә) җөмләнең иярчен кисәге булып килә;*
*б) җөмләнең баш кисәге дә, иярчен кисәге дә булып килә.*
5. Ясалма алмашлыкларны күрсәтегез.
*а) кайчан, ничаклы, һичкайда, һичбер,никадәр, һәрбер;*

*ә) кем, нәрсә,мин, син, бу, теге, үз, һәр;*
*б) тегеләй, андый, мондый, тегенди, нинди, болай, алай;*
*в) ул-бу, андый – мондый, алай – болай, аннан- моннан;*
*г) әллә кем, әллә кайда, кем дә булса, кайчан да булса.*
6. Асыл сыйфатларга
*а) төр ясагыч кушымчалар гына ялгана;*
*ә) төрләндерегеч кушымчалар гына ялгана;*
*б) ясагыч кушымчалар гына ялгана.*
7. Мәгънә һәм вазифиларына карап, алмашлыклар
*а) 5 төркемчәгә бүленә;*
*ә) 6 төркемчәгә бүленә;*
*б) 7 төркемчәгә бүленә.*
8. Җыю саннары исемне ачыкламый, аларның саналмышлары булмый. Шуңа күрә алар җөмләдә
*а) аергыч була алмый;*
*ә) күбесенчә хәл булып киләләр;*
*б) баш кисәкләр генә булалар.*
9. Хәл фигыльнең дүртенче төре
*а) үзе бәйләнгән фигыльдәге эштән соң була торган эшне, хәлне белдерә;*
ә) *үзе ачыклап килә торган фигыльдәге эштән алда булган эшне, хәлне белдерә.*
10. *Кадәр, чаклы, хәтле, тикле* бәйлекләре, юнәлеш килешендәге исемнәрдән соң килгәндә
*а) күләм яки микъдар ягыннан чагыштырыну белдерә;*
*ә) охшату, чагыштыру* мәгънәсендә кулланыла;
б) *урын яки вакыт чиген белдерә.*

**Тикшерү эше №7.** Тема: Синтаксис бүлеген йомгаклау.

**Диктант. Әкияти манзара.**

**Максат:**укучыларның синтаксис бүлеге буенча булган белем дәрәҗәләрен тикшерү, Тикшерү эшенең эчтәлеге синтаксис бүлеге буенча булган белемнәрен дөрес итеп куллана белүләрен тикшерүгә юнәлтелгән:

**Грамматик биремнәр:**

- бирелгән җөмләләргә синтаксик анализ ясау;
- җөмләләр арасында тыныш билгеләрен дөрес кую;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау тәртибен дөрес куллану.

**Критерии оценки знаний учащихся:** диктант
Отметка «5» выставляется за безошибочную работу;
отметка «4» выставляется при наличии 2 орфографических, 2 пунктуационных, или 1 орфографической и 3 пунктационных ошибок;
отметка «3» выставляется при наличии 4 орфографических, 4 пунктуационных, или 3 орфографической и 5 пунктационных ошибок;
отметка «2» выставляется выставляется при наличии 7 орфографических, 6 пунктуационных, или 6 орфографической и 5 пунктационных ошибок;

**Критерии оценки знаний учащихся на грамматическое задание:**
Отметка «5» ставится за 95-100% правильных ответов
отметка «4» ставится за 94-85% правильных ответов
отметка «3» ставится за 84-50% правильных ответов
отметка «2» ставится, если правильно выполнено менее 50% заданий

Диктант. Әкияти манзара.

1)Зариф урман юлына аяк басуга, ут шары офыкка алсу пәрдә элеп юкка чыкты. 2)Урман тын кебек иде. 3)Очларын күккә төбәгән усак агачларының өске ябалдашлары, ялкын телләрен хәтерләтеп, айкалып-чайкалып тора. 4) Аяк астындагы абага үләне, мулла чалмасы, бакра гөл, кыңгырау чәчәкләр, курай, балтырган, юл читенә елышкан киң яфраклы тигәнәк – һәммәсе, үз төсләрен югалтып, кичке шәфәкъ нурыннан әкияттәге гөлләргә охшап калганнар. 5) Каршыдагы Рә тавы үсеп-зураеп киткән сыман, шуларның барысыннан да күңелгә шөбһә иңә, йөрәккә шом төшә.6) Ул да түгел, тау артыннан ялангач ай калыкты, тирә-юнь чынлыгын югалтып, күз күрә алган һәммә нәрсә әкият манзараларына әверелде. 7)Рә тавы – гүя Каф тавы, урман исә – балта-пычкы тимәгән карурман.

Күк йөзенә төнге пәрдә сарды, йолдызлар җемелди башлады. Тын кебек иде, ләкин дикъкать белән тыңласаң, күрәсең-ишетәсең: баш өстеннән генә ярканат очып уза, аның канат җиле битеңне ялмап ала; ирексезләп, кулың сакка күтәрелә. Биредәге һәр тавыш, һәр аһәң гаммадай көчәеп, яңгырап, куәтләнеп китә, күңелнең иң нечкә кылларына кагыла, йөрәккә әллә ниткән шом сала, нииндидер мизгелдә, барча тавыш юкка чыга; йөрәк тибүең ишетәсең. Ләкин бу тынлык озакка бармый, урманны яңгыратып, тартай кычкырып җибәрә, аңа байгыш ухылдавы өстәлә, кыр-басу ягыннан бытбылдык аваз сала, аларга бакалар кушыла. Түбән карасаң, черек агач төбендә ут коңгызлары җемелди, сөрсеп, кибеп беткән яфрак астында сукыр тычкан кыштырдый.

*(М.Хәбибуллиннан)* (200 сүз)

**Бирем.**

1.Тексттагы 1-7 нче җөмләләргә синтаксик анализ ясарга.

2.1,2.3нче җөмләләрдәге исемнәргә морфологик анализ ясарга.

**Тикшерү эше №8.** Тема: Туган телдән еллык контроль эш

**Максат:**укучыларның туган тел буенча булган белем дәрәҗәләрен тикшерү, Тикшерү эшенең эчтәлеге фонетика, морфология, синтаксис бүлекләре буенча булган белемнәрен дөрес итеп куллануга юнәлтелгән:

**Грамматик биремнәр:**

- бирелгән җөмләләргә синтаксик анализ ясау; .
- сүзләрнең ясалышын дөрес билгеләү
- җөмләләр арасында тыныш билгеләрен дөрес кую;
- биремдәге баш, иярчен кисәкләрне дөрес табу, асларына сызу
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау тәртибен дөрес куллану.

**Критерии оценки знаний учащихся: Диктант.**

Отметка «5» выставляется за безошибочную работу;
отметка «4» выставляется при наличии 2 орфографических, 2 пунктуационных, или 1 орфографической и 3 пунктационных ошибок;
отметка «3» выставляется при наличии 4 орфографических, 4 пунктуационных, или 3 орфографической и 5 пунктационных ошибок;
отметка «2» выставляется выставляется при наличии 7 орфографических, 6 пунктуационных, или 6 орфографической и 5 пунктационных ошибок;

**Критерии оценки знаний учащихся на грамматическое задание:**

Отметка «5» ставится за 95-100% правильных ответов
отметка «4» ставится за 94-85% правильных ответов
отметка «3» ставится за 84-50% правильных ответов
отметка «2» ставится, если правильно выполнено менее 50% заданий

Диктант. Беренче ау.

Аучылар барлыгы йөз егерме кеше булды. Алардан тыш, төп-төгәл мең кешелек каралар җыелды. Болары төрле эшчеләр, сугымчылар, өйчеләр иде. Беренче ауга – тархан авына шуннан да азрак яисә күбрәк кеше алынмый иде.

Иң алдан аучылар китте. Алардан бераз калышып, каралар кузгалды. Алар көнчыгышка карап бардылар. Арттан бик үк көчле булмаган салкын җил исте. Югарыга күтәрелгән саен кечерәеп күренгән аксыл-саргылт кояш яктысында, бер болытсыз чалт аяз күк йөзе астында иксез-чиксез дала җәелеп ятты. Йөзләгән, меңләгән тояклар таптавына җавап итеп, каты җир өсте гүләп-дөпелдәп торды.

Кояш төшлеккә җиткәнче, алар шактый кызу бардылар. Кояш төшлеккә җитеп, түбәнәя башлаганда, аучылар тирә-ягында тәбәнәк таллар, карама куаклары, камышлар үскән елга буена килеп чыктылар. Аркача дип аталган бу елга моннан ике көн ераклыктагы Кара тау арасындагы Кылыч кыя төбеннән, куе урман арасыннан агып чыга иде. Бу тирәдә ул, тигез җирдә җәелеп, тынычланып ага иде һәм монда инде аның ярлары да текә түгел, агымы да кискен, шау-шулы түгел иде. Елганың чит-читләрен бүген төнлә юка боз элпәсе каплап алган иде. *(Н.Фәттахтан)* (150 сүз)

***Бирем.***

2.Кояш төшлеккә җиткәнче, алар шактый кызу бардылар ***җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз.***

***3.*** Аучылар, көнчыгышка, аксыл-саргылт, башлаганда, бераз, эшчеләр, арттан, күк йөзе, меңләгән ***сүзләренең ясалыш ягыннан төрен билгеләгез.***

***4.*** Елганың чит-читләрен бүген төнлә юка боз элпәсе каплап алган иде ***җөмләсендәге баш һәм иярчен җөмлә кисәкләрен табыгыз***.

**5. Аучылар, салкын, юка, матур, иксез-чиксез сүзләрен синоним парлар табып язарга**

**6.Тексттан парлы сүзләрне табып язарга, кайсы сүз төркеменә караганын әйтергә.**

## Кулланылган әдәбият

**Студентлар өчен:**

1**.** Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 нчы с-ф. - Р.К. Сәгъдиева. - Казан: "Мәгариф – Вакыт" нәшр., 2017. - 247 б.

2**.** Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 11 нчы с-ф. - Р.К. Сәгъдиева. - Казан: "Мәгариф – Вакыт" нәшр., 2017. - 286 б.

## Фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү

| **Укыту нәтиҗәсе<br>( белергә, эшләргә тиеш)** | **Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары** |
|---|---|
| **Укучыларның үзләштерергә тиешлебелем – күнекмәләре:**<br>1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.<br>2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.<br>5. Язу тарихын тирән белү.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.<br>2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.<br>5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.<br>9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу. | Изложение; диктант; тестлар; реферат; сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү. |